***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ

**ҖАВАПЛАРЫ**

(2024-2025 нче уку елы)

**4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 54**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Саңгырау тартык авазлардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) өстәл
   **ә) китап**
   б) дәфтәр
   в) бетергеч

2. Парсыз яңгырау тартыкны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [җ]
   ә) [г]
   б) [д]
   **в) [н]**

3. Калын сузык авазлардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) бүре
   ә) төлке
   **б) куян**
   в) керпе

4. Хәрефләр белән авазлар саны тигез булмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) яфрак**
   ә) көньяк
   б) яшьлек
   в) кулъюгыч

5. ***Соң*** сүзенең антонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кич
   ә) озын
   б) көндез
   **в) иртә**

6. Парлы сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кара(җиләк)
   **ә) исән(сау)**
   б) ай(сыз)

в) бал(корты)

7. Урын-вакыт килешендәге исемне билгеләгез. **(2 балл)**
а) урман
ә) урманга
б) урманны
**в) урманда**

8. Хәзерге заман хикәя фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
**а) укый**
ә) укыган
б) укыды
в) укыр

9. Санны билгеләгез. **(2 балл)**
а) укучы
ә) ул
**б) ун**
в) саныйм

10. Боеру җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) Нинди матур көн!
ә) Урамда кар явамы?
**б) Балалар, кар бабай ясагыз!**
в) Балалар урамда уйныйлар.

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Татар телендә нечкә һәм калын сузык авазлар була. О һәм ө хәрефләре сүзнең беренче иҗегендә генә языла. Охшаш мәгънәле сүзләр синонимнар дип атала. Аш, аша, ашлык – тамырдаш сүзләр. -га/-гә – юнәлеш килеше кушымчасы. Сыйфатлар предметның төрле билгеләрен белдерәләр. Фигыль эш-хәрәкәтне белдерә. Ия кем? нәрсә? сорауларына җавап бирә.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Эш сөйгәнне ил сөйгән. Ялкауның көн дә башы авырта. **(4 балл)**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**
Ученики сейчас на уроке.
Они читают и пишут по-татарски.
Алсу делает домашнее задание медленно.

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

Трамвайда барганда,
Әгәр дә минем янда
Олылар басып барса,
Ә мин утырган булсам –
Җәһәт кенә торам да
Урын бирәм аларга.
(*Ямаш Игәнәй*)

2.1. Сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(2 балл)**
олылар – **кечкенәләр** басып – **утырып**
2.2. ***Җәһәт*** сүзенең синонимын языгыз. **(1 балл) (тиз)**
2.3. Зат алмашлыкларын күчереп языгыз, килешләрен билгеләгез. **(3 балл)**
(**мин** – б.к., **минем** – и.к., **аларга** – ю.к.).
3. **"Өлкәннәргә булышам"** темасына 6-8 җөмләдән торган инша языгыз. **(10 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2024-2025 нче уку елы)
**5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 54**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Яңгырау тартык авазлардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кайнатма
   ә) шикәр
   б) коймак
   **в) гөбәдия**

2. Парсыз саңгырау тартыкны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [ф]
   ә) [т]
   **б) [һ]**
   в) [ч]

3. Җөмләдәге [э] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Һәр эшнең дә җае бар, ботканың да мае бар.* (Мәкаль)
   а) 1
   **ә) 2**
   б) 3
   в) 4

4. Юлдан-юлга күчереп булмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) егет**
   ә) йолдыз
   б) елга
   в) кояш

5. ***Тәмле*** сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) тәмле күмәч
   ә) тәмле кайнатма
   **б) тәмле төш**
   в) тәмле аш

6. Тезмә сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) бал(сыз)
   ә) кара(бодай)

б) кием(салым)
**в) бака(яфрагы)**

7. Тартым белән төрләнгән исемне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) песиләр
   **ә) песиебез**
   б) песинең
   в) песиләргә

8. Алмашлыкны билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) алар**
   ә) укучылар
   б) җитмеш
   в) йөгерә

9. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кечкенә
   ә) кечкенәрәк
   **б) кеп-кечкенә**
   в) бәләкәй

10. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**
    *Укучылар агач ботагына җимлек элделәр.*
    **а) укучылар**
    ә) агач
    б) ботагына
    в) җимлек

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Татар телендә нечкә һәм калын сузык авазлар була. Татар телендә басым, гадәттә, сүзнең соңгы иҗегенә төшә. Капма-каршы мәгънәле сүзләр антонимнар дип атала. Сыз, сызык, сызыклы – тамырдаш сүзләр. -ны/-не – төшем килеше кушымчасы. Саннар предметның исәбен белдерәләр. Боерык фигыльләр зат-сан белән төрләнәләр. Ия кем? нәрсә? сорауларына җавап бирә.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Болганчык су тирән күренә. Бер тамчыдан диңгез булмый. **(4 балл)**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

Моя комната небольшая.

Около окна стоит письменный стол.
На столе лежат мои учебники и тетради.
В шкафу висит моя одежда.

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

КЫЕН ХӘЛ

Ишегалды бозлавык,
Бозлавыкта бер тавык.
Тукта, тукта, ни булды?
Тавык таеп егылды!
Әтәч килде ярдәмгә,
калды кыен бер хәлгә:
ярдәм итәр юлы юк.
Канаты бар, кулы юк.

(*Рөстәм Мингалим*)

2.1. Кушма сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) (ишегалды)** (артык сүз язылса, балл киметелә!)
2.2. ***Ярдәм итәр*** сүзенең синонимын языгыз. **(2 балл) (булышыр)**
2.3. Шигырьдә кулланылган антоним сүзләрне парлап языгыз. **(2 балл) (тавык – әтәч, бар – юк)**
2.4. Тойгылы җөмләне күчереп языгыз. **(1 балл) (Тавык таеп егылды!)**
3. Йорт хайваннары, кош-кортлары турында 6-8 җөмләдән торган инша языгыз. **(10 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2024-2025 нче уку елы)
**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 58**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге [э] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Дөрес эш өчен кыю басып тор.* (Мәкаль)
**а) 1**
ә) 2
б) 3
в) 4

2. Кече тел тартыгын билгеләгез. **(2 балл)**
а) [һ]
ә) [й]
б) [ф]
**в) [х]**

3. Басымы соңгы иҗеккә төшкән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
а) аңлатасың
ә) аңлаталар
**б) аңлаттылар**
в) аңлатмадылар

4. Антонимнарны билгеләгез. **(2 балл)**
а) кача, яшеренә
ә) уйный, шаяра
**б) кайгыра, шатлана**
в) яна, балкый

5. Фразеологизмның синоним парын билгеләгез. **(2 балл)**
***түшәмгә төкереп яту***
а) стенага борчак ату
**ә) корыны бушка аудару**
б) тетмәсен тетү
в) сабын куыгы очыру

6. Тамырдаш сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**
а) шат, таш

ә) күл, күлмәк
**б) бүл, бүлмә**
в) кискеч, бетергеч

7. Тартым белән төрләнгән исемне билгеләгез. **(2 балл)**
а) кош
ә) кошчык
б) кошларга
**в) кошчыгым**

8. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
а) якты
ә) яктырак
**б) яп-якты**
в) уттай

9. Җөмләдәге фигыльнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Аю – көченә, кеше акылына ышана.* (Мәкаль)
**а) хәзерге заман хикәя фигыль**
ә) үткән заман хикәя фигыль
б) киләчәк заман хикәя фигыль
в) боерык фигыль

10. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**
*Яңа ел бәйрәмен балалар шатланып көтеп алалар.* (Мәкаль)
а) Яңа ел
ә) бәйрәмен
**б) балалар**
в) көтеп алалар

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Татар телендә авыз һәм борын тартык авазлар була. Сүзләрнең мәгънәләре аңлатмалы сүзлекләрдә күрсәтелә. Күп мәгънәле сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре була. Сүзнең нигезе тамырдан яки тамыр һәм ясагыч кушымчадан тора. -ның/-нең – иялек килеше кушымчасы. Без, сез, алар – зат алмашлыклары. Хикәя фигыльләр зат-сан белән төрләнәләр. Ия һәм хәбәр – җөмләнең баш кисәкләре.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Холкы начардан дуслары качар. Кешенең акылы сүзеннән билгеле. **(4 балл)**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

Меня зовут Елизавета. Я приехала из Москвы. В школе изучаем татарский язык. На уроке мы часто читаем вслух.

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

Кояшлы уены

Яуды яңгыр, яуды яңгыр,
Күлләвекләр җыелды.
Чулт-чулт итеп агачлардан
Шук тамчылар коелды.
Шатлыгыннан кош сайрады,
Кояш чыкты ялтырап.

**Ап-ак томан җиргә ятты**
**Иртә таңнан, ял сорап.**
Әнә салават күпере –
Ал, кызыл басмалары,
Гүя ул нәни кызларның
Чәчүргеч тасмалары.

(*Эльмира Шәрифуллина*)

2.1. Сингармонизм законының ирен гармониясенә буйсынган сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) (коелды)** <u>(артык сүз язылса, балл киметелә!)</u>

2.2. Борын ассимиляциясе күзәтелгән сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл) (шатлыгыннан, таңнан)** <u>(артык сүз язылса, балл киметелә!)</u>

2.3. Фигыльдән ясалган исемнәрне күчереп языгыз. **(2 балл) (тамчылар, басмалары)** <u>(артык сүз язылса, балл киметелә!)</u>

2.4. ***Кызыл*** сыйфатын дәрәҗәләр белән төрләндереп языгыз. **(2 балл) (кызыл, кызылрак, кып-кызыл, кызгылт)**

2.5. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләнең хәбәрен языгыз. **(1 балл) (ятты)**

3. **“Җәйге яңгыр”** дигән темага 8-10 җөмләдән торган инша языгыз. **(12 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2024-2025 нче уку елы)
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 60**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Җөмләдәге [**й**] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Көн саен майлы ботка булмый.* (Мәкаль)
а) 1
ә) 2
**б) 3**
в) 4

2. Калын пары булмаган сузык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
а) [ү]
**ә) [и]**
б) [ә]
в) [ө]

3. Җөмләдәге ябык иҗекләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Ялкауга яңгыр иң беренче төшә.* (Мәкаль)
а) 4
ә) 5
**б) 6**
в) 7

4. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
***канат астына алу***
а) качыру
ә) урлау
б) кочаклау
**в) яклау**

5. Татар теленең үз сүзен билгеләгез. **(2 балл)**
**а) икмәк**
ә) дәфтәр
б) кәбестә
в) шагыйрь

6. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) аллы(гөлле)

ә) кура(җиләге)

**б) кара(җиләк)**

в) мал(туар)

7. Чама санын билгеләгез. **(2 балл)**

а) унау

**ә) меңнәрчә**

б) уникешәр

в) өч бөтен уннан бер

8. Юклык алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) алар

ә) сезнеке

б) нинди

**в) һичкем**

9. Җөмләдәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

*Бүгенге эшне иртәгә калдырма*. (Мәкаль)

**а) сыйфат, исем, рәвеш, боерык фигыль**

ә) сыйфат, исем, рәвеш, хикәя фигыль

б) рәвеш, исем, рәвеш, боерык фигыль

в) сыйфат, исем, исем, боерык фигыль

10. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Оятсыз кеше өчен оятлының йөзе кызарыр.* (Мәкаль)

а) оятсыз

ә) кеше

б) оятлының

**в) йөзе**

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Сузыкка тәмамланган иҗек – ачык иҗек. [һ], [щ], [х], [ц] – парсыз саңгырау тартыклар. Исемнең иркәләү-кечерәйтү кушымчасы – модальлек кушымча. Язылышлары төрле, әйтелешләре бертөрле булган сүзләр омофоннар дип атала. Татар телендә алты килеш бар. Кыскартылма исемнәр сүзләрнең беренче иҗекләреннән ясала ала. Боерык фигыль эш кушуны, үтенүне белдерә. Хикәя җөмлә ахырына нокта куела.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Көндезге эш кичке эштән көләр. Караңгы төннән соң якты көн килә. **(4 балл)**

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

Мы готовим домашнее задание. Я повторяю старые слова, а подруга учит новые глаголы. Потом мы читаем недлинный текст, повторяем правила и пишем упражнения.

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

ИРТӘ БЕЛӘН

Җып-җылы, нурлы көн бүген.
**Бер кош юына тышта.**
Гаҗәпләнәм: үзе нәни,
Ә үзе нинди чиста!

Чирәмдәге чык суында
Коена да коена.
Аның чәчкән тамчылары
Җанлы сыман тоела.

Канатына ышкып ала
Нәни генә томшыгын.
Шифалы, тылсымлы диләр
Яландагы таң чыгын...

(*Галимҗан Гыйльманов*)

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл) (чиста, шифалы)** <u>(артык сүз язылса, балл киметелә!)</u>
2.2. Тартыклар чиратлашуы күзәтелгән сүзләрне күчереп языгыз. **(3 балл) (бүген, томшыгын, чыгын)** <u>(артык сүз язылса, балл киметелә!)</u>
2.3. ***Шифалы*** сүзнең синонимын языгыз. **(2 балл) (савыктыргыч/ сихәтле...)**
2.4. Кушма сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) (бүген)**
2.5. ***Җылы*** сыйфатының кимлек дәрәҗәсен языгыз. **(1 балл) (җылымса)**
2.6. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләнең хәбәрен языгыз. **(1 балл) (юына)**

3. **“Канатлы дусларыбыз”** дигән темага 8-10 җөмләдән торган инша языгыз. **(12 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2024-2025 нче уку елы)
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 60**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Җөмләдәге [**м**] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Көчең белән мактанма, эшең белән мактан.* (Мәкаль)
   а) 1
   ә) 2
   б) 3
   **в) 4**

2. Җөмләдәге ачык иҗекләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Берәүнең буе кыска, берәүнең уе кыска.* (Мәкаль)
   а) 5
   ә) 7
   **б) 8**
   в) 10

3. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***усак яфрагы***
   а) кечкенә кеше
   **ә) тиктормас, кыбырсык кеше**
   б) яшь, тәҗрибәсез кеше
   в) тырыш, эшчән кеше

4. Татар теленең үз сүзен билгеләгез. **(2 балл)**
   а) шәһәр
   ә) хат
   б) вәгъдә
   **в) авыл**

5. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) уен(көлке)
   **ә) тере(көмеш)**
   б) кара(бөрлегән)
   в) каз(үрдәк)

6. Вакыт рәвешен билгеләгез. **(2 балл)**

а) сишәмбе
ә) шактый
б) кич
**в) бүген**

7. Затланышсыз фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**

а) боерык фигыль
ә) шарт фигыль
**б) исем фигыль**
в) хикәя фигыль

8. Сүзтезмәне билгеләгез. **(2 балл)**

а) диңгез
**ә) тирән диңгез**
б) диңгез, күл
в) Кара диңгез

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Читлеккә* ***өйрәнгән*** *кош ректә башын югалтыр*. (Мәкаль)
а) ия
ә) хәбәр
б) рәвеш хәле
**в) аергыч**

10. Җөмләнең хәбәрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Сукыр тычканга карт мәче дә арыслан булып тоела*. (Мәкаль)
а) сукыр
ә) мәче
б) булып
**в) тоела**

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Юнәлеш килешендәге I һәм II зат алмашлыклары рәт гармониясенә буйсынмыйлар. Язылышлары бердәй, әмма әйтелешләрендә аерма булган сүзләр омографлар дип атала. Бер тамырдан булган сүзләр – тамырдаш сүзләр. Сыйфат предметның яисә затның төрле билгеләрен белдерә. Саналмыш һәрвакыт берлек санда килә. Җөмләдәге сүзләр арасында тезүле һәм иярүле бәйләнеш була. Урын хәле беркайчан да аерымланмый.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Карчыга авызыннан ит кире чыкмый. Вак балык көтүе белән йөри. **(4 балл)**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

На уроке ученики читают вслух, пишут, рассказывают, много говорят по-татарски. Иногда они отвечают правильно, иногда неправильно. Когда дети говорят неправильно, учительница исправляет их ошибки.

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

ТАҢ

Таң ата, дип ишеткән бар
Әбидән дә, бабайдан да.
Ә үземнең таң атканын
Күргәнем юк беркайчан да.
Бүген менә **шуңа күрә**
Уяндым да караңгыдан,

"Таң ничек ата соң?" – диеп
Карап торам тәрәзәдән.
Башта үзем куркып куйдым:
Караңгыда күрә алмам.
Хәзер тышта якты инде,
Таң атканын күрми калмам.

*(Равил Фәйзуллин)*

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) (беркайчан)**

2.2. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне күчереп языгыз, басымнарын билгеләгез **(3 балл) (бе′ркайчан, ме′нә, ни′чек, а′лмам, кү′рми, ка′лмам)**

2.3. Иртүк торуны белдергән фразеологизмны искә төшереп языгыз. **(2 балл) (таң тишегеннән)**

2.4. Кушма сүзләрне күчереп языгыз. **(1 балл) (беркайчан, бүген)** (артык сүз язылса, балл киметелә!)

2.5. ***Якты*** сыйфатын дәрәҗәләр белән төрләндереп языгыз. **(1 балл) (яктырак, яп-якты)**

2.6. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмлә кисәгенең төрен языгыз. **(2 балл) (сәбәп хәле)**

3. Шигырьдәге геройны тасвирлап, 8-10 җөмләдән торган инша языгыз. **(12 балл)**

*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2024-2025 нче уку елы)
**9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 68**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге [**а**] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Оясыз сандугач сайрамый*. (Мәкаль)
   а) 3
   ә) 4
   **б) 5**
   в) 6

2. Җөмләдәге ачык иҗекләр санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Куркак аулакта батыр була*. (Мәкаль)
   а) 3
   **ә) 4**
   б) 5
   в) 8

3. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***сакал сыйпап калу***
   **а) алдану**
   ә) саубуллашу
   б) изге теләкләр теләп калу
   в) борчылу

4. Татар теленең үз сүзен билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) теләк**
   ә) хыял
   б) өмет
   в) гомер

5. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кием(салым)
   ә) җир(су)
   б) эт(шомырты)
   **в) яр(канат)**

6. Билгеләү алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) кемдер
ә) кайда
**б) һәркем**
в) берни

7. Затланышлы фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**

а) исем фигыль
**ә) боерык фигыль**
б) хәл фигыль
в) сыйфат фигыль

8. Сүзтезмәне билгеләгез. **(2 балл)**

а) җиләк
**ә) баллы җиләк**
б) җиләк-җимеш
в) кура җиләге

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Куркакның йодрыгы* ***кесәсендә.*** (Мәкаль)
а) ия
**ә) хәбәр**
б) урын хәле
в) тәмамлык

10. Мәкальләр арасыннан кушма җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Аннан-моннан эшләсәң, яңадан эшләрсең.
ә) Иренгәннең иренен эт ялаган.
**б) Ир мактаныр, корал эшләр.**
в) Иренмәгән иртәгәге эшен бүген бетергән.

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

[и] авазының калын пары юк. Татар телендә ачык һәм ябык иҗекләр бар. Бер иҗекле сүзгә басым тамгасы куелмый. Билгеле бер грамматик формада гына омоним булып килгән сүзләр омоформалар дип атала. Парлы сүзләр сызыкча аша языла. *Ул* зат һәм күрсәтү алмашлыгы була ала. Тиңдәш кисәкләрдән соң килгән гомумиләштерүче сүз алдыннан сызык куела. Баш кисәкләрдән генә торган җөмлә җыйнак җөмлә дип атала.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Коралда кырык кешенең көче бар. Кулыңнан килмәгән эшкә тотынма. **(4 балл)**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

Верблюд – одно из самых выносливых животных. Несколько недель он может идти под палящим солнцем и не пить. При этом он ещё и груз несёт. Поэтому верблюд для человека в пустыне незаменим. Его называют “кораблём пустыни”.

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

УРМАН

Тезелеп үскән төрле зур агачлар,
Үзе матур, үзе куркыныч;
**Яшел хәтфә кебек яфраклары**
**Кайвакытта тора тып-тыныч.**

Тып-тын торган ошбу серле урман,
Төрле матур кошлар оясы;
Матур кошларына табигатьнең
Бүләк итеп биргән дөньясы.

*(Мәҗит Гафури)*

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл) (табигатьнең, дөньясы)** <u>(артык сүз язылса, балл киметелә!)</u>

2.2. Искергән сүзне һәм аның кайсы сүз төркеменә караганлыгын языгыз. **(2 балл) (ошбу – алмашлык)**

2.3. Шигырьдә кулланылган синонимнарны языгыз. **(1 балл) (тып-тыныч, тып-тын)**

2.4. Тартым белән төрләнгән исемнәрне күчереп языгыз. **(2 балл) (яфраклары, оясы, кошларына, дөньясы)** <u>(артык сүз язылса, балл киметелә!)</u>

2.5. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләгә синтаксик анализ ясагыз: җөмлә кисәкләрен һәм аларның төрләрен билгеләгез, җөмләгә билгеләмә бирегез. **(4 балл)**

<u>Яшел</u> <u>хәтфә кебек</u> <u>яфраклары</u> (г.и.)
<u>Кайвакытта</u> (в.х.) <u>тора</u> (г.ф.х.) <u>тып-тыныч</u> (р.х.).
Бу – раслау, хикәя, җәенке, ике составлы, тулы гади җөмлә; тиңдәш һәм аерымланган кисәкләре юк; инверсия (кире сүз тәртибе).

3. ***“Серле урман”*** дигән темага 10-12 җөмләдән торган инша языгыз. **(15 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2024-2025 нче уку елы)
**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 68**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Җөмләдәге [**ө**] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Йолдыз бик югары да, ул да кое төбенә төшә.* (Мәкаль)
   а) 2
   **ә) 3**
   б) 4
   в) 5

2. Җөмләдәге ачык иҗекләр санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Ялкау ятып эшли, утырып йоклый.* (Мәкаль)
   а) 3
   **ә) 4**
   б) 5
   в) 6

3. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***мыегы үрә тору***
   а) бик каты мактану
   ә) бик каты шатлану
   **б) бик каты ачуы килү**
   в) бик каты борчылу

4. Татар теленең үз сүзен билгеләгез. **(2 балл)**
   а) келәм
   ә) диван
   б) өстәл
   **в) суыткыч**

5. Җөмләдәге тамыр сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   *Иртәгәге эшеңне бүген эшлә.* (Мәкаль)
   а) иртәгәге
   **ә) эшеңне**
   б) бүген
   в) эшлә

6. Юклык алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

а) минеке
ә) ничек
б) һәрбер
**в) һичкем**

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**

***Күмәк*** *эш – күңелле эш.* (Мәкаль)
**а) сыйфат**
ә) исем
б) рәвеш
в) фигыль

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Курыккан эт* ***кырга*** *чыкмас.* (Мәкаль)
а) ия
ә) тәмамлык
**б) урын хәле**
в) рәвеш хәле

9. Икеләнүне белдерә торган кереш сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) зинһар
**ә) мөгаен**
б) ниһаять
в) ичмасам

10. Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Малай, кулына акча керсә, көчек сатып алыр.* (Мәкаль)
а) синтетик иярчен урын җөмлә
ә) синтетик иярчен вакыт җөмлә
б) аналитик иярчен шарт җөмлә
**в) синтетик иярчен шарт җөмлә**

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Уңай һәм кире ассимиляция була. Элек тә һәм хәзерге көндә дә еш кулланыла торган сүзләр актив сүзләр дип атала. Тамыр нигезле һәм ясалма нигезле сүзләр була. Исем килеш, сан һәм тартым белән төрләнә. Гарәп цифрларыннан соң килгән кушымчалар аерым языла. Боерык фигыль заман белән төрләнми. -ның/-нең кушымчалы сүз җөмләдә исемгә иярсә, ул аергыч була. Мөнәсәбәтле сүз һәрвакыт баш җөмләдә килә.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Ялкау кешенең җилкәсе чокыр булыр. Ялкауның кулы куеныннан чыкмас. **(4 балл)**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

Я увидел ёлку. Росла она в тени, и оттого сучья у неё были опущены вниз. Под ёлкой получился хороший шалашик.

Невозможно передать прелести пребывания в лесу под ёлкой во время тёплого летнего дождя. Долго дождик шептал и шептал что-то нашей ёлке. *(М.Пришвин)*

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

САКЛЫЙК, ӘЙДӘ, ҖИР-АНАНЫ
Чиста һава – җанга дәва, беләбез,
Сихәт эзләп, урманнарга керәбез.
Сафланырга шәһәр сарган сөремнән
Елга-күлләр хозурына киләбез.
Кошлар тынса, урман бетсә, күл кипсә,
Җирдә яшәү булалмасын төшенәм.
**Я, кем белә: ничек итеп якларга**
**Зур Җир шарын бәп-бәләкәй кешедән**?
(*Сания Әхмәтҗанова*)

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл) (чиста, дәва)** <u>(артык сүз язылса, балл кимetelә!)</u>
2.2. Рече тел ассимиляциясе күзәтелгән сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) (җанга)**
2.3. Шигырьдә кулланылган синонимнарны языгыз. **(1 балл) (дәва, сихәт)**
2.4. 1-2 җөмләләрдәге затланышсыз фигыльләрне күчереп языгыз. **(3 балл) (эзләп, сафланырга, сарган)** <u>(артык сүз язылса, балл кимetelә!)</u>
2.5. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләгә синтаксик анализ ясагыз: баш кисәкләрнең астына сызыгыз, компонент чикләрен билгеләгез, схема сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. **(4 балл)**

(1)Я, <u>кем</u> <u>белә</u>: (2)ничек итеп <u>якларга</u>
Зур Җир шарын бәп-бәләкәй кешедән.
(1 – б.ж., 2 – а.и.т.ж. күтәрү интонациясе – бәйләүче чара). Бу – иярченле кушма җөмлә. Схема сызылырга тиеш!

3. ***“Җир-ананы саклыйк!”*** дигән темага 10-12 җөмләдән торган инша языгыз. **(15 балл)**

***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2024-2025 нче уку елы)
**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 70**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге [**ө**] авазының санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Төлке тиресе белән, былбыл өне белән кадерле.* (Мәкаль)
а) 2
ә) 3
**б) 4**
в) 5

2. Җөмләдәге ябык иҗекләр санын билгеләгез. **(2 балл)**
*Булыр-булмас эшне алдан шаулап йөрергә кирәкмәс*. (Мәкаль)
а) 8
ә) 9
**б) 10**
в) 12

3. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
***ут борчасы***
а) мактанчык
**ә) бик тере, хәрәкәтчән**
б) бик ачулы
в) бик булдыклы

4. Алынма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
**а) эшләпә**
ә) яулык
б) күлмәк
в) итәк

5. Җөмләдәге тамыр сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Җәяүле атлыга юлдаш булмый*. (Мәкаль)
а) җәяүле
ә) атлыга
б) юлдаш

**в) булмый**

6. Күрсәтү алмашлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) күпме
   ә) сезнеке
   **б) шунда**
   в) ниндидер

7. Затланышсыз фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) барса
   **ә) барырга**
   б) бар
   в) бардык

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**
   *Туры **юлдан** олы юл яхшы.* (Мәкаль)
   **а) тәмамлык**
   ә) урын хәле
   б) рәвеш хәле
   в) шарт хәле

9. Раслауны белдерә торган кереш сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) димәк
   ә) беренчедән
   б) бәхеткә
   **в) һичшиксез**

10. Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
   *Ун адәм салган күперне бер адәм бозар*. (Мәкаль)
   а) аналитик иярчен аергыч җөмлә
   **ә) синтетик иярчен аергыч җөмлә**
   б) синтетик иярчен урын җөмлә
   в) синтетик иярчен тәмамлык җөмлә

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(8 балл)**

Уңай ассимиляция язуда чагылыш таба. Татар телендә ике ачык иҗек бар. Синонимик ояда иң еш кулланыла торган доминанта сүз була. Җыю санының саналмышы булмый. Исем фигыль – затланышсыз фигыль. -ның/-нең кушымчалы сүз җөмләдә фигыльгә иярсә, ул тәмамлык була. Раслау һәм инкяр җөмләләр була. Иртүче теркәгечләр һәрвакыт иярчен җөмләдә килә.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Кеше үз кадерен үзе арттырыр. Һичкемне үзеңнән түбән уйлама. **(4 балл)**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

Хуже нет для полевых и лесных зверьков, чем малоснежное начало зимы! Голая земля промерзает все глубже, становится твёрдой, как камень.

Но вот повалил снег. Сухое снежное море покрывает землю. На дне снежного моря теплее, чем на его поверхности. Сюда не попадает леденящий ветер. *(В.Бианки)*

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

ИКЕ ФӘЛСӘФӘ

Яшь кешенең фәлсәфәсе шундый:
Бәхет эзләр офыклардан ары.
Сүзсез генә яшен коеп торыр
Бакча артындагы тупыллары.

Карт кешенең фәлсәфәсе башка:
Туган якка юлы, туган якка.
Моңаешып калган тупыллары
Ничә еллар буе шунда тарта?

Туган яктан күңел бизәме соң?
Җырлары да моңлы, сагынганга.
Мөлдерәшеп, күз яшьләре тама,
Тупылларга килеп кагылганда.

(*Фәйрүзә Мөслимова*)

2.1. Беренче куплеттагы сингармонизм законының ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз. **(3 балл) (офыклардан, коеп, торыр)** (артык сүз язылса, балл кимételә!)
2.2. Кече тел ассимиляциясе күзәтелгән сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) (сагынганга)**
2.3. Икенче куплеттагы алынма сүзләрне языгыз. **(2 балл) (фәлсәфәсе, тупыллары)** (артык сүз язылса, балл кимételә!)
2.4. ***Офык*** сүзенең синонимын языгыз. **(1 балл) (горизонт, күк чите)**
2.5. Икенче куплеттагы затланышсыз фигыльләрне күчереп языгыз. **(2 балл) (моңаешып, калган)** (артык сүз язылса, балл кимételә!)
2.6. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләгә синтаксик анализ ясагыз: баш кисәкләрнең астына сызыгыз, компонент чикләрен билгеләгез, схема сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. **(4 балл)**
(1)Яшь кешенең фәлсәфәсе шундый:
(2)Бәхет эзләр офыклардан ары.
(1 – б.җ., 2 – а.и.х.җ. *шундый* – бәйләүче чара). Бу – иярченле кушма җөмлә. Схема сызылырга тиеш!

3. ***“Туган ягым һәм минем киләчәгем”*** дигән темага 10-12 җөмләдән торган инша языгыз. **(15 балл)**